**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**Урыссу ш.т.п.** **№10** **17.07.2017 ел**

***Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 2014 елның 7 маендагы " "Җирле салымнар, пенялар, штрафлар һәм бу салымнар буенча недоимканы түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында" 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында***

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 2014 елның 7 маендагы 5 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 8,9,10 абзацлар өстәргә:

- 3 елдан артык бурыч барлыкка килгән җирле салымнар буенча;
- җирле салымнар буенча, суд приставы тарафыннан башкаручы тарафыннан «Башкару производство турында» 02.10.2007 ел, № 229-ФЗ Федераль законның 46,47 ст.1 өлешенең 3,4 п. билгеләнгән очракларда башкарма документны түләттерүчегә кире кайтару турында өстәмә производствоны тәмамлау турында карар чыгарганда.
- гамәлдән чыгарылган җирле салымнар һәм җыемнар буенча, реструктуризация режимында һәм бөлгенлек (банкротлык) процедураларында булган салым түләүчеләргә бурычлардан тыш.

2. Әлеге карарны «Ютазы таңы» («Ютазинская новь») газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында jutaza.tatar.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталына урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башлыгы -
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы Рәисе Р.М. Нуриев